| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Девятернинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Девәтернә авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2024 Девәтернә авылы № 53-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советының 31.05.2023 елның 33-1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымтада бирелгән үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://www.agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карар, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Э.Э. Ганиев

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районы Девәтернә авыл җирлеге
Советының 12.12.2024 елның
53-1 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр**

1) 5 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

2) 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:
«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

3) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
7 статья. Муниципальара хезмәттәшлек рәвешләре

1. Муниципальара хезмәттәшлек түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) муниципаль берәмлекләрнең муниципаль берәмлекләр берләшмәләрендә әгъзалыгы;

2) муниципальара хуҗалык җәмгыятьләрен, муниципальара матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм челтәр басмасын оештыру;

3) муниципаль берәмлекләр тарафыннан коммерциягә карамаган оешмалар оештыру;

4) шартнамәләр һәм килешүләр төзү;

5) Россия Федерациясе субъектлары муниципаль берәмлекләре советларының үзара хезмәттәшлеген оештыру.»;

4) 11 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирлек Советы депутатларын сайлаулар «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау Кодексында билгеләнгән тәртиптә уздырыла.»

5) 14 статьяның 3 өлешендәге 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

6) 24 статьяның 5 өлешендәге 2 абзацында «әлеге Федераль законның 40 статьясындагы 10 өлешенең 1-7 пунктларында» сүзләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6

октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 10 өлешенең 1-7 һәм $9^2$ пунктларында» сүзләренә алмаштырырга»»;

7) 31 статьяның 1 өлешендәге 24 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;

8) 38 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:

«$9^1$) ул чит ил агенты статусын алгач;»;

9) 47 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктының 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра;»

10) 47 статьяның 1 өлешендәге 10 пунктына түбәндәге эчтәлекле тугызынчы абзац өстәргә:

«- ) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

11) 57 статьяның икенче абзацында «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга.

12) 60 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$) аның чит ил агенты статусын алуы;»;

13) 68 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«68 статья. Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып алар:

1) Тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; ЭЛ № ФС77-60244 массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык 17.12.2013 елда

Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзәр) тарафыннан бирелгән);

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру (https://agryz.tatarstan.ru);

3) Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Девәтернә авылы, Совет ур., 48 нче йорт адресы буенча урнаштыру.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен түбәндәге адрес буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пункты эшли: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Девәтернә авылы, Совет ур., 48 нче йорт.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Җирлек Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән үз көченә керә.

7. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган вакытлы матбугат басмаларының, челтәр басмаларының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтларның домен исемнәрен һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы белешмәләр күрсәтелгән исемлеген халыкка җиткерү Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән башкарыла.».